**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтешшәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2025 № 983

**"2026-2030 елларга Тәтеш муниципаль районының мәгариф системасын үстерү" муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итү максатларында, халыкның үзгәреп торучы таләпләре һәм җәмгыятьне һәм икътисадны үстерүнең перспектив бурычлары нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2030 елларга Тәтеш муниципаль районы мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын (алга таба – Программа) кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Тәтеш муниципаль районы мәгариф системасын үстерү «муниципаль программасын раслау турында»22.12.2020 ел, № 686 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Тәтеш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (А.А. Богданов) ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын төзегәндә Программа чараларын гамәлгә ашыруга, мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм шул максатларга Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә акча каралга.
4. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә PRAVO.TATARSTAN.RU, шулай ук Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында
5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының программаны гамәлгә ашыруда катнашучы структур бүлекчәләренә программада каралган чараларны вакытында үтәүне тәэмин итәргә.
6. Район Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм документлар әйләнеше бүлегенә (А.В. Алексеев) әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.В.Николаевага йөкләргә.

Җитәкче И.А.Садриев